КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 ноябрь г.Казань № 1114

Татарстан Республикасы территориясендәге мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү кыйммәте нормативларын һәм эш режимы 12 сәгать булган каравыл постлары санын билгеләү турында

«Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның $5^1$ статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендәге мәгариф оешмалары (алга таба – мәгариф оешмасы) объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү кыйммәте нормативларын түбәндәгечә расларга:

беренче куркынычлылык категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен – бер каравыл посты өчен сәгатенә 150 сум күләмендә;

икенче куркынычлылык категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен – бер каравыл посты өчен сәгатенә 150 сум күләмендә;

өченче куркынычлылык категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен – бер каравыл посты өчен сәгатенә 130 сум күләмендә.

2. Бер мәгариф оешмасында эш режимы 12 сәгать булган каравыл постлары санын түбәндәгечә билгеләргә:

беренче куркынычлылык категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен – 2 каравыл посты;

икенче куркынычлылык категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен – 1 каравыл посты;

өченче куркынычлылык категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен – 1 каравыл посты.

3. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин